ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында” Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм “Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында” 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 өлешнең 4 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән хәлләрне раслау өчен кирәкле документлар, шулай ук әлеге статьяның 3 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына караган һәм дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнаша торган оешмалар эш итүендә булган документлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 09 апреле
№ 20-ТРЗ